**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 март № 138

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләрен сату турында» 2012 ел, 3 октябрь, 827 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләрен сату турында» 2012 ел, 3 октябрь, 827 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 15 февраль, 105 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясы белән күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрен мондый биналар, корылмалар йә алардагы бүлмәләр милекчеләренә сату турында»;

карарның преамбуласындагы «36 статьясы» сүзләрен «39.4 статьясы» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренең аларда урнашкан биналарны, төзелешләрне йә алардагы бүлмәләрне сатканда кыйммәтен билгеләү өчен Татарстан Республикасында кулланыла торган җир (алга таба – җир кишәрлекләре) бәясе түбәндәгеләрне тәшкил итә дип:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2013\105.doc